**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы**
**Олы Шәмәк авыл җирлегенең Олы Шәмәк торак пунктында**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**21 ноябрь 2019 ел** **№ 2**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Олы Шәмәк авыл җирлегенең Олы Шәмәк торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районыны Олы Шәмәк авыл җирлегенең Олы Шәмәк пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлар, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Тәтеш картлар һәм инвалидлар интернат йорты» социаль хезмәт күрсәтү дәүләт автоном учреждениесеннән социаль хезмәт алучылар, күпбалалы гаиләләр, балачактан инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның һәм аларның тол хатыннары, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына хезмәткә чакырылган гражданнар, ирektән мәхрүм итү урыннарындагы гражданнардан тыш, 2020 елда 700 сум күләмендә үзара салым кертүне гамәлгә ашырырга.

2. Аннан алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен, түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлдерергә:

- Олы Шәмәк авылы эчендәге Мәктәп ур., Пролетарская ур., Ленин ур., Кутузов ур., Совет ур. юлларны төзекләндерү;
- Олы Шәмәк авылы зираты территориясен койма белән әйләндереп алу;
- Олы Шәмәк авылында урам яктырткычлары һәм лампалары сатып алу һәм алыштыру;
- Олы Шәмәк авылына чүп контейнерлары сатып алу;
- Олы Шәмәк авылында карт агачларны кисү.

**Халык җыенында**
**рәислек итүче** **А.И. Афанасьев**

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Олы Шәмәк авыл җирлеге башлыгы** **А.И. Афанасьев**